# Удмуртия Язучылар берлегенә – 90 ел

Эльмира НИГЪМӘТҖАН



**15 ноябрь көнне УР Милли китапханәсендә Удмуртия Язучылар берлегенең 90 еллыгына багышланган тантаналы чара узды. Анда Удмуртиядә яшәүче шагыйрьләр, язучылар, шулай ук аларның иҗатын бәяләүче әдәбият сөючеләр, Дәүләт органнары вәкилләре, җәмәгатьчелек һәм Удмуртия Республикасы муниципаль берәмлекләреннән кунаклар катнашты.**

Удмуртия Республикасы Башлыгы һәм Хөкүмәте хакимияте җитәкчесе **Александр Журавлев** чарада катнашучыларны сәламләп: «1934 ел – Удмуртиянең әдәби



Татьяна Ишматова Гөлфия Исхаковагы бүләкли

тарихында мөһим бит. 90 ел элек Удмуртия Язучылар берлеге оешкан. Бер гасырга якын вакыт эчендә ул төрле буын авторлары өчен әдәбият дөньясына юл күрсәтүчегә әверелеп, укучылар һәм фикердәшләр табарга ярдәм итә. Бүгенге көндә Удмуртиянең әдәби бергәлегендә йөздән артык язучы, шагыйрь һәм драматург бар. Төрле елларда иҗат иткән Кузебай Герд, Кедра Митрей, Григорий Верещагин кебек танылган авторлар Удмуртиянең горурлыгы булып тора. Аларның эшен замандашларыбыз дәвам итә. Һәр чыгарылган китапта Удмуртия халкының гореф-гадәтләре, рухы, ватанпәрвәрлек һәм илгә мәхәббәт чагыла. Соңгы елларда махсус хәрби операция темасына да игътибар бирелә. Минем Удмуртиядә яши башлавыма нибары ел ярым гына булса да, кечкенә кызым белән «Кузебай» китап кибетендә еш булам. Ул – удмурт әкиятләрен, мин Флор Васильевның шигырьләрен үз иттем.

Бүгенге көндә Удмуртия Башлыгы мәдәниятебез үсешенә зур игътибар бирә. Ә Язучылар берлегенең юбилее «90 ел Ватанга хезмәт итәбез» дип аталган зур әдәби фестиваль форматында узуы бик үзенчәлекле. Барыгызны да бәйрәм белән котлыйм. Авторларга зур хезмәтләре, эшкә тугрылыклары өчен рәхмәт белдерәм. Китапларыгыз үз укучыларын тапсын!» – дип билгеләп үтте. Ул УР Башлыгының Рәхмәт хатларын тапшырды, дәрәҗәле исемнәр алучыларны игълан итте. Удмуртиянең халык язучысы исеменә прозаик, журналист, «Кизили» балалар журналының элеккеге мөхәррире Өлфәт Бәдретдинов ия булды. «Инвожо» журналының баш мөхәррире, Язучылар берлеге рәисе Петр Захаровка һәм удмурт бард хәрәкәтенә нигез салучы Владимир Котковка Республиканың халык шагыйре исеме бирелде.

Удмуртия Язучылар берлеге әгъзаларын Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, фән, мәгариф, гражданлык җәмгыяте институтларына ярдәм итү буенча даими комиссия рәисе **Татьяна Ишматова**: «Удмуртиядә язучылар һәм шагыйрьләр саны артканнан-арта бара. Чын күңелдән котлауларны кабул итегез!» – дип, каләм ияләрен Дәүләт Советының Рәхмәт хатлары, Мактау грамоталары белән билгеләп үтте.

Бу кичне Удмуртия Язучылар берлеге әгъзалары мәдәният министры урынбасары **Эдуард Лавров** кулыннан Мәдәният министрлыгының Рәхмәт хатларын, Мактау грамоталарын алдылар.

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе **Александр Валов**: «Бүген Удмуртия Язучылар берлеге – ул йөздән артык әдәбиятчы. Алар турында республикабызда гына түгел, аннан читтә дә беләләр. Алар бергәләп хәзерге заман нәфис сүз культурасының нигезен булдыралар, әсәрләр бастыралар, әһәмиятле проектларны тормышка ашыралар, конкурслар, фестивальләр, әдәби очрашулар, презентацияләр, хәтер акцияләре үткәрәләр. Бу эшчәнлек Удмуртиянең әдәби мирасына кызыксынуны арттыра», – дип билгеләп үтте. Ул әдәбият һәм нәшрият эшлеклеләрен агентлыкның Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары белән билгеләп үтте.

Удмуртия Язучылар берлеге оешканнан бирле Россия Язучылар берлеге белән тыгыз хезмәттәшлек итә. Юбилей тантанасында да **Россия Язучылар берлеге рәисе Николай Ивановны** күрү язучылар өчен шатлыклы күренеш булды. Николай Иванов журналист, язучы, публицист, 30дан артык китап авторы буларак билгеле. Аның җәмәгать эшлеклесе буларак казанышлары Россия Федерациясе Президентының Рәхмәте белән билгеләп үтелгән. Хәрби журналист һәм язучы сыйфатында төрле елларда Әфганстанда, Чечняда, Цхинвалда, Кырымда, Донбасста,



Гүзәл Исхакова Петр Захаров белән

Сүриядә була. «Советский воин» журналы һәм «Налоговая полиция» газетасының баш мөхәррире булып хезмәт куя. Хәрби журналист, Мәскәүдә «Брянское землячество» иҗтимагый оешмасы әгъзасы.

Тантананың мәртәбәле кунагы кичәдә катнашучыларны юбилей белән котлады һәм: «Сезнең республикада тудырылган мохитне, хакимиятнең иҗади кешеләргә мөнәсәбәтен күреп шатланам. Бүгенге бүләкләр дә шуның дәлиле. Халык язучылары һәм шагыйрьләре сафы өч яңа исем белән тулыланды, һәм бу безнең уртак горурлыгыбыз», – дип, Удмуртия Башлыгы командасына рәхмәт белдерде.

Николай Иванов Петр Захаровка тантаналы рәвештә истәлекле бүләк – Россия Язучылар берлеге флагын тапшырды.

Николай Иванов Россия Язучылар берлеге идарәсе исеменнән катнашучыларны мөһим бәйрәм белән котлады һәм Рәхмәт хатлары тапшырды.

Удмуртия Язучылар берлеге күп кенә проектларда катнашкан: сүзләр фестивалендә, «Шигъри микрофон»да, «Рувики» Россия интернет-энциклопедиясе оештырган төбәк язучылары турында мәкаләләр бәйгесендә, удмурт авторлары әсәрләре буенча спектакльләр һәм концертларда, «Әдәби Хәтер десанты»нда. «Хәзер без гамәлдәге проектларны дәвам итеп кенә калмыйбыз, яңаларын булдыру өстендә дә эшлибез. Шулай ук көн тәртибендә – берлеккә яшь авторларны җәлеп итү һәм традицион кыйммәтләрне саклауга һәм патриотизм тәрбияләүгә юнәлдерелгән әсәрләр иҗат итүгә ярдәм итү. Берләшмә тормышында балалар өчен проектлар аерым урын алып тора. Без Удмуртия мәктәпләрендә һәм балалар лагерьларында патриотик юнәлештәге дәресләр үткәрәбез, балалар конкурслары оештырабыз. Быел 100дән артык укучы «Бу көн гомерлеккә истә калачак» дип исемләнгән республика эссе конкурсында катнашты, – дип билгеләп үтте Удмуртия Язучылар берлеге рәисе **Петр Захаров**.

Удмуртия Республикасы Язучылар берлегенең юбилее уңаеннан һәм «Ватанга 90 ел хезмәт итәбез» әдәби фестивале кысаларында УР Язучылар берлеге удмурт, рус һәм татар телләрендә гражданлык-патриотик юнәлештәге әсәрләргә (поэзия һәм проза) конкурс игълан иткән иде. Кичәдә Петр Захаров әлеге конкурсның йомгаклау басмасын тәкъдир итте.

Юбилей кичәсендә шулай ук мәктәп укучылары арасында «Бу көн гомерлеккә истә калачак» темасына республика эссе конкурсына, «Рувики» Россия интернет-энциклопедиясе оештырган Удмуртия язучылары турында язмалар конкурсына да йомгак ясалды. Аның мәкаләләре Россия халыкларының 20 телендә, шул исәптән



Зөлфия Мимидиминова Николай Иванов белән

удмурт телендә дә тәкъдим ителде.

«Айкай» дәүләт фольклор җыр һәм бию театры (җитәкчесе – Петр Данилов), Удмуртиянең атказанган һәм халык артисты Геннадий Бекманов, «Зангари»халык җыры һәм бию ансамбле кичәгә бәйрәм кәефе бүләк итте.

Ә мине сөендергәне – бүләкләнүчеләр арасында татар милләтеннән дә язучылар булуы. Каләмдәшебез Гөлфия Исхакова – Удмуртия Республикасы Дәүләт Советының Рәхмәт хаты, ә Гүзәл Исхакова – Удмуртия Милли сәясәт министрлыгының Мактау грамотасы, Зөлфия Мимидиминова Россия Язучылар берлегенең Мактау грамотасы белән бүләкләнде. Барлык редакциябез хезмәткәрләре исеменнән аларны әлеге уңышлары белән котлыйбыз!